**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет төзү турында» 2013 елның 30 гыйнварындагы ПУ-71 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1098 номерлы, 2016 елның 7 маендагы ПУ-405 номерлы, 2017 елның 17 апрелендәге ПУ-310 номерлы, 2018 елның 13 апрелендәге ПУ-308 номерлы, 2018 елның 6 июлендәге ПУ-473 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2020 елның 17 апрелендәге ПУ-236 номерлы, 2020 елның 5 ноябрендәге ПУ-727 номерлы, 2021 елның 16 февралендәге ПУ-147 номерлы, 2022 елның 6 октябрендәге ПУ-715 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 6 апрелендәге 213 номерлы һәм 2024 елның 27 апрелендәге 306 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан А.С. Герасимовны, Н.Н. Джураевны, М.А. Скоблионокны чыгарырга;

б) Совет составына түбәндәгеләрне кертергә:

Арзамазов Алексей Андреевичны – «Татарстан Республикасының удмурт милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисен;

Дамар Диларә Фикърәт кызын – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе каршындагы Татарстан халыклары Яшьләр ассамблеясе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы рәисен (килешү буенча);

Плискин Аркадий Дмитриевичны – «Татарстан Республикасының яһүд милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисен (килешү буенча);

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

А.А. Абдусаттаровның – «Татарстан Республикасының үзбәк милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча)»;

Г.Ф. Габдрахманованың – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты» аерымланган структур бүлекчәсе этнология тикшеренүләре бүлеге мөдире (килешү буенча)»;

В.Е. Козловның – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институты директораты директорының фәнни эшчәнлек буенча урынбасары (килешү буенча)»;

В.Н. Любченконың – «Татарстан Республикасында «Берләштерелгән украин милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 28 март
№ 240